МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_10.03.2020_ Казан ш. №_35-ОД_

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2017 елның 19 декабрендәге 310-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны электрон рәвештә формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2017 елның 19 декабрендәге 310-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.5 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (хезмәт эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш), яисә гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслый торган башка документлар һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр;».

2. Юридик бүлек башлыгына әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Эш башкару һәм контроль бүлегенә (Л.В. Авдошина) әлеге боерыкны Министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләренә җиткерергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны министр урынбасары А.Ш. Хөсәеновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер министры
урынбасары – министр А.Ә.Кәримов